

ТАРТУ КӨЧЕ

Актаныш районының Чиялек авылы халкы, без бетәбез, дигәннәрдән түгел

> 2



МИЛЛӘТ ХӘТЕРЕ

«Җыен» фонды бөек шәхесләрнең мирасын барлау эшен дәвам итә

> 3

ЯНӘ «АВАНГАРД»

«Ак барс» икенче ел рәттән Омск командасына оттырып, Гагарин Кубогы өчен көрәштән төшеп калды

> 4

59 нчы БӘЙГЕ

Көрәшчеләр газетабызның Муса Җәлил истәлегенә узучы турнирына әзерләнә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 35 (28808) | Сишәмбе | 15 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Вазгыять

Көн саен үзгәреп торган вазгыятьтә хакимияттән дә, бизнестан да, халыктан да яңа шартларга тиз арада җайлашу сәләтен күрсәтү сорала. Ярдәм чаралары булганда файдаланырга, бәяләрне йөгәнләргә, эш урыннарын сакларга – Татарстан шул юнәлештә эш итәргә җыена. Көнбатыш санкцияләренә җавап итеп нинди чаралар күрелер? Хакимият чикләнгән вазгыятьтә чикләнмичә яшәү мөмкинлекләрен барлады.

Уртак җаваплылык

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хакимият органнары вәкилләренә уртак бурыч куйды: җитештерүчәнлекне һәм эш урыннарын саклап калу. Аның сүзләренчә, төрле тармакларга, кече һәм урта эшкуарлык вәкилләренә федераль дәрәҗәдә ярдәм күрсәтү күздә тотыла. Үзебезнекеләрне республика да онытмаячак.

– Эш урыннарын һәм җитештерүчәнлекне саклап калырга кирәк. Иң мөһиме – халыкны азык-төлек белән тәэмин итү, даруларга, медицина эшләнмәләренә, көнкүреш товарларга кытлык булдырмау. Халыкка, шул исәптән балалы гаиләләргә ярдәм итү зарур. Бәяләр үсешен булдырмый калуга да аерым игътибар итәргә кирәк, – диде ул.

Бу бурычларны үтәүдә Президент кушуы буенча оешкан оператив штабның ике юнәлештә эш алып баручы комиссиясе җаваплы. Чикләүләргә бай узган атнада алар нинди эш башкарган? Татарстанның икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов шул хакта хисап тотты.

Штабның төп бурычы – халыкны беренчел ихтыяҗ кирәк-яраклары белән тәэмин итү. Министр сүзләренчә, сәүдә нокталарында алар җитәрлек дәрәҗәдә. Барысы да элеккечә эшләвен дәвам итә. Кибет киштәләренең товарлар белән тәэмин ителешен көн саен тикшереп торалар. Тарату үзәкләрендә дә (распределительные центры. – **Ред.**) товар кытлыгы юк. Икмәк, икмәк ризыклары белән тәэмин итүче предприятиеләрнең эшчәнлеге бозылмасын өчен, шикәр һәм он запасларының резерв фонды булдырылган. Район хакимият вәкилләренә дә, министрлыкларга да бәяләрнең нигезсез үсешен булдырмаска кушылды. Андый очраклар турында Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсенә хәбәр итәргә кирәклеге искәртелде.

Бәя уйнавы халыкның үзеннән дә тора, әлбәттә. Кибеттәге хәлләр коронавирус пандемиясе яңа башланган чакларны искә төшерде. Халык ул чакта да «кирәге чыгар әле» дип азык-төлек, башка кирәк-ярак җыйды. Хәзер дә эт чаба дип, бет чаба кебек. Кирәгеннән артык алынган тоз, шикәр, ярма белән нишләп бетәр икән соң халык? Һәрхәлдә, бер ай эчендә файдаланып бетерәселәре шик тудыра. Әнә «Авито» һәм башка игъланнар сайтларында үз бәясенә сатып алган товарларны берничә мәртәбә арттырып саткан «акыллы» кешеләр күренгәли башлады инде. Үз тамагың кадерлерәк чакта кеше хакында уйлыйсы килми. Үзебезгә берничә айлык запас туплау, йә булмаса вазгыятьтән файдаланып калу теләге бүтәннәрне – мохтаҗракларны ач калдырмасын иде.

tatarstan.ru

БӘЯ ДӘ ҮСМӘСЕН, ЭШСЕЗЛӘР ДӘ АРТМАСЫН

ТАТАРСТАН ЧИКЛӘҮЛӘРГӘ НИЧЕК КАРШЫ ТОРАЧАК?

Татарстан Президенты «Телеграм» каналында да кайбер товарлар бетә икән дип коткы таратырга кирәкмәвен искәртте. «Шикәргә бәйле күп сораулар килә. Складта товар бар. Киштәгә тезеп салуга, сатып алып бетерәләр. Шикәрне үзебезнең Зәй шикәр заводы җитештерә. Алга таба да әлеге продукция белән ул тәэмин итәчәк. Ыгы-зыгы тыначак, бу вакытлыча», – дип язган ул.

Тарату үзәкләрендә дә азык-төлек, башка төр товар күләме җитәрлек. Әйтик, X5 Retail Group үзәгендә (ул «Пятерочка», «Перекресток», «Карусель» кибетләренә товар бүлеп бирә) запаста продукциянең 6 меңләп төре бар. Соңгы арада карабодай ярмасы, он, шикәргә ихтыяҗ зур икән. Складта тәкъдим ителгән товарның 32 процентын Татарстан җитештерүчеләре били.

Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов «Татхимфармпрепараты» җәмгыятендә шәхсән булып, иң кирәкле даруларны җитештерү эше ничек оештырылуын да карап кайтты. Хәзерге вакытта биредә даруның 131 төрен чыгаралар, шуларның 60ы тормыш өчен кирәкле булган препаратлар исемлегенә керә. Боларның бәясен дәүләт үзе көйли. Президентка фармацевтика өлкәсендәге яңа эшләнмәләр турында да сөйләделәр. Араларында импортка алмаш булырдай тәкъдимнәр дә яңгырады. Әйтик, трансплантология юнәлешендәге «Феломика», «Такролимус» препаратлары, онкология авыруларын дәвалауда куллану өчен «Абиратерон» һәм «Капецитабин», даруларны алга таба җитештерү өчен махсус чимал. Бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов дару җитештерүчеләргә ярдәм күрсәтү чаралары турында уйларга кушты.

Президент яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин итү эше белән дә шәхсән танышты. Россия технологияләрен кулланып эш иткән «Майский» комплексында елына 43 мең тонна яшелчә үстерәләр. Рөстәм Миңнеханов хәбәр иткәнчә, комбинат үз продукциясен авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә дә тәкъдим итәчәк. Мәгълүм булганча, ярминкәләр 19 марттан башлана.

Ахыры 2 нче биттә >

Төзелеш туктамаячак

Санкцияләр кертүгә карамастан, «Мәскәү – Казан» М12 трассасы төзелеше вакыты чигерелмәячәк, чит ил техникасы белән проблемалар булса да, туктамаячак. Бу хакта Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин хәбәр итте.

«Импорт күләме зур түгел – 7 процент. Барлык проект эшләрен яңадан карап чыктык. Асфальт түшәү эшендә проблема бар. Аларны төзекләндерү сорала. Электрга бәйле сораулар да бар, әмма барысын да яңадан карап чыккач, хәл итеп булачак, бу төзелеш вакытына тәэсир итмәячәк. Киресенчә, хәзер мин көн саен төзелеш эшен тизләтү буенча утырышлар оештырам», – дип белдергән вице-премьер «Россия 1» каналы эфирында.

Марат Хөснуллин фикеренчә, төзелеш тизлеген арттырып җибәрү инфляция йогынтысын киметү өчен дә кирәк.

«Акрынрак эшлибез икән, моның өчен күбрәк түлибез дигән сүз. Шуңа күрә мин тәүлек буе эшләүне оештыру, өстәмә ярдәмнән файдалану бурычын куям. Бу вазгыятьтә тизлек – ул акча», – дигән вице-премьер.

Шартлары билгеле

Россия Хөкүмәте ил халкына кредит каникулыннан файдалану шартларын билгеләде. Премьер-министр Михаил Мишустин банкларга кредитны кичектерүне сорап мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек биргән ссуда күләме турында карарны имзалады.

Кулланучылар кредиты буенча лимит түбәндәгечә: физик затларга – 300 мең, шәхси эшмәкәрләргә – 350 мең, кредит картасы буенча – 100 мең, автокредитка – 700 мең сум.

Ипотека кредиты буенча лимит дәрәҗәсе төбәкләр буенча аерыла. Әйтик, Мәскәү өчен бу – 6 млн, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы төбәкләренә – 4 млн сум. Россиянең башка төбәкләре өчен – 3 млн сум.

Кредит каникулын сорап 2022 елның 30 сентябренә кадәр мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Хәзерге керемнең, узган елгы уртача табыш белән чагыштырганда, 30 процентка кимегән булуы шарт. Ташламалы кредит каникулын 1–6 айга кадәр алырга була.

Искәртеп үтик: кредит каникулы 2022 елның 1 мартына кадәр рәсмиләштерелгән барлык төр (ипотека, куллану, автокредит) кредитларга бирелә.

Ил халкы нигә борчыла?

Эшсезлек, җинаятьчелек һәм бәя үсү. Россиядә яшәүчеләрнең төп куркулары шул икән. Бу хакта Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге җитәкчесе Валерий Федоров белдергән.

Аның сүзләренчә, халык инфляциядән, аның артыннан товарларга бәя артудан шүрли. Кешеләр күнегелгән тормыш рәвешен үзгәртергә туры килер һәм киләчәккә планнары бозылыр дип борчыла.

Валерий Федоров әйтүенчә, күпләр җинаятьчелек артуыннан курка. Сораштыру барышында халыкның коронавирустан элеккеге кебек курыкмавы ачыкланган.

Хокук сакчылары сак булырга өнди

Татарстанда террорчылык куркынычы турында ялган хәбәр тарату очраклары арткан. Бу хакта Федераль иминлек хезмәтенең (ФСБ) республикадагы идарәсе хәбәр итә. Хокук сакчылары җиткергән мәгълүматка караганда, мондый хәбәрләр чит илдә урнашкан электрон почта аша таратыла.

Моннан тыш, Украинада урнашкан кәрәзле элемә операторлары аша шалтыратып, Россия хәрби хезмәткәрләре турында мәгълүматлар җыю, Татарстанда рөхсәт ителмәгән чаралар оештыруга һәм аларда катнашырга чакыру очраклары да арткан. Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәтендә коткыга бирелмәскә, шикле мәгълүматны җентекләп тикшерергә, рөхсәт ителмәгән чараларда катнашмаска, интернет аша таратылган хәбәрләр турында хокук сакчыларына җиткерергә киңәш итәләр.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Көнүзәк мәсьәлә

Хәзер мәҗбүри түгел

Татарстанда аерым төркем кешеләргә мәҗбүри вакцина ясату таләбе бетерелде. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина кичә шул хакта карар имзалады.

«Республика халкын яңа коронавирус инфекциясенә каршы иммунизацияләүне анализлап, шуны билгеләп үтәм: COVID-19га каршы мәҗбүри вакцинация ясатырга тиешле кешеләр төркеме арасында коллектив иммунитет дәрәҗәсе 2022 елның 10 мартына 80 проценттан артып китә», – ди Марина Патяшина. Билгеле булганча, узган елның 11 октябрендә Татарстанда аерым төркем кешеләргә коронавируска каршы прививка ясату таләбе үз көченә кергән иде. Бу иң беренче чиратта 60 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк кешеләр, медицина, белем бирү, социаль, сәнәгать һәм төзелеш оешмаларында, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләргә, хокук саклау органы, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләргә кагылды.

8 ноябрьгә кадәр алар коронавируска каршы вакцинаның беренче, 6 декабрьгә кадәр икенче компонентын ясатырга тиеш иде. Бу таләпне үтәмәгән хезмәткәрләр исә, Татарстанның баш санитар табибы карары нигезендә, эштән азат ителергә тиеш иде. «Хәзер исә шул сәбәпле эштән азат ителгән кешеләрнең барысы да кире үз эш урыннарына кайта ала. Яңа имзаланган карар шуны күздә тота», – дип ачыклык керттеләр Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсендә.

Хәзерге вакытта Татарстанда 2,45 миллион кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Узган тәүлектә Татарстанда коронавирус йоктыруның 592 яңа очрагы теркәлгән. Вирус йоктыручыларның 98е хастаханәдә дәвалана. Россия күләмендә исә бер тәүлек эчендә чиргә бирешүчеләр саны 6 меңнән арткан. Пандемия башланганнан бирле Татарстанда барлыгы 131150 кеше коронавирус йоктырган. 1791 кешенең гомере өзелгән. Ил күләмендәге саннарга күз салсак, Россиядә барлыгы 84,4 миллион кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Бер тәүлек эчендә чир йоктыручылар саны 6 меңнән арткан. Пандемия башланганнан бирле исә Россиядә барлыгы 17,38 миллион кеше коронавирус йоктырган, 361,1 мең кешенең гомере өзелгән.

Хәтерләсәгез, әле февраль азагында гына Татарстанда QR-кодлар да бетерелгән иде. Элегрәк эре сәүдә үзәкләренә, җәмәгать туклану урыннарына фәкать шушы код буенча гына кереп була иде. Хәзер бу чикләүләр дә юк. Март башында исә тамаша һәм концерт залларын 100 процент тутыру рөхсәт ителде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы спикеры:

Күпләр, азык-төлек запасы җыеп, продуктларга ихтыяҗ арттырып, 90 нчы елларны искә төшерә. Әмма без башка вакытта яшибез. Берәү дә проблемалар белән япа-ялгызы калмаячак. Азык-төлек җитми, дип борчылырга сәбәп юк. Мондый ажиотаж спекулянтлар өчен файдага гына.

(Шәхси «Telegram» каналында язганнардан)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ АЛУ

«РИА Рейтинг» агентлыгы Россиядә яшәүчеләрнең кредит алу буенча активлыгын тикшергән һәм «бурычлы төбәкләр» исемлеген төзегән. Бер ел эчендә ил халкының кредит алу дәрәҗәсе 49,1 проценттан 55,6 процентка арткан.

Урын	Төбәк	Ел башында кредит буенча бер кешегә уртача бурыч һәм еллык хезмәт хакы, %	Бер кешенең банкка уртача бурычы (мең сум)
1	Ингушетия	12,0	39,2
2	Чечня	23,1	74,6
3	Дагыстан	25,1	84,4
...			
69	**Татарстан**	**73,6**	**344,5**
...			
83	Удмуртия	83,0	334,2
84	Тыва	90,0	433,3
85	Калмыкия	103,5	358,4

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГЛОБАЛЬ ТҮНТӘРЕЛЕШ АЛДЫННАН

Үткән атна ахыры дөнья сәясәтендә тектоник плитәләрнең кызу хәрәкәте белән үзенчәлекле булды. Планета масштабында турбулентлык көчәя. Сүз да юк: Мәскәү – Киев конфликты вакыйгаларның үзәгендә тора. Байден инде Америкадагы бәяләр күтәрелешендә Россияне гаепләп өлгерде. Дөньяның финанс базарларында инде бер ай тирәсе салмак кына түбәнәю бара, котировкалар гел «кызыл зона»да диярлек. Газета хәбәрчесе: «Кытайның кыйммәтле кәгазьләре нык түбәнәя. Трейдерлар Кытайның Тайваньга һөҗүменнән куркалар», – дигән хәбәр алды. Американың дәүләт эшлеклесе Джордж Пападопулус: «Россия, Кытай һәм Иран Байденны ныклыкка тикшерәләр», – дип белдерде. Иран тиктомалдан гына телгә алынмый, чөнки шимбәдән якшәмбегә каршы төндә Иран территориясеннән Гыйракның Әрбаласына төгәл ракеталар белән күәтле һөҗүм ясалды. Таң алдыннан алынган беренче хәбәрләрдә: «Фарсылар АКШ объектларына һөҗүм иттеләр, консуллык утка тотылды», – дигән сүзләр бар иде. Бу уңайдан Байденның милләткә мөрәҗәгате дә әзерләнүе мәгълүм булды. Хәл бик киеренке иде, хәтта мәгълүмат кырына америкалылар Иранга һөҗүм итәчәкләр дигән фаразлар да чыкты. Ләкин соңыннан Вашингтон Иран һөҗүме америкалыларга каршы булмавын әйтеп тынычландырды. Тәһраннан да ракеталар Гыйрак Көрдстанындагы Израиль базасына төшүен хәбәр иттеләр. Бу Израильнең Сүриядәге Иран хәрбиләрен үтерүенә җавап икән.

Шимбәдән якшәмбегә каршы төндә газета хәбәрчесе: «Согуд Корольлеге башкаласында авыр бәрелешләр булды», – дигән хәбәр дә алды. Әмма хәбәрнең монысы киң мәгълүмат кырына чыкмады, асылы шуңа күрә билгеле булмады. Тик бу юлларның авторы гел искәртә: Якын Көнчыгыш дөньякүләм үзгәрешләрнең авангардына чыгачак бервакыт.

Хәзер инде өзек-өзек хәбәрләрне бер киштәгә тезеп карыйк. Бүген Көнбатыш өчен иң актуаль мәсьәлә – нефть һәм газ. Вашингтон һәм Тәһран соңгы көннәрдә килешү сукмагына бастылар, чөнки базарга Иран нефте кирәк. Россияне тезләндерүнең стратегиясе шуны таләп итә. Венесуэлага каршы санкцияләр дә шул сәбәпле йомшартылды. Каракас инде нефть чыгаруны арттырырга вәгъдә бирде. Россиянең аркадашы, Мәскәүдән зур суммада акча алып торган ил җинел генә америкалылар кубызына биергә әзер тора. Каракасны аңлап була, чөнки Латин Америкасындагы бу илдә икътисади хәл бик катлаулы. Вашингтон дипломатиясе ярыйсы гына җимешләрен бирә: углеводородларга рекордлы рәвештә күтәрелгән бәяләр ярыйсы гына төште. Нефть һәм газ бәяләренең түбәнәюенең тагын бер сәбәбе бар: глобаль икътисади түнтәрелеш якынлаша. Россия белән Украина арасындагы конфликтны да шул китереп чыгарды инде нигездә: ил лидерлары халыкның игътибарын шуңа юнәлтеп, финанс түнтәрелешенә сылтау табарга телиделәр. Алар бу максатларына ирештеләр дә: дөньяның кайсы гына телеканалын ачып карама, тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә Украинадагы хәлләргә тап буласың. Коронавирус онытылды, финанс проблемалары телгә алынмый. Әмма да ләкин Кытайда зур финанс шартлавы әзерләнә. Монысы инде башка конфликтларга этәргеч бирергә хикмал. Байден бернинә көн элек кенә: «Өченче Бөтендөнья сугышы башланса да, Украинадан түгел», – диде.

Россиядә

КИЕВ – МӘСКӘҮ: КИЛЕШҮ БУЛЫРМЫ?

Украинада барган вакыйгалар барыбызны да бик сызландыра һәм әрнетә, билгеле. Танклар, авиация, ракеталар кулланып алып барылган махсус хәрби хәрәкәтләр корбаннарсыз гына була алмый. Җитмәсә, үткән атнада хәрби хәрәкәтләр театрында борын асты кибеп бетмәгән малайларның да булуы ачыкланды. Владимир Путин да инде чакырылыш нигезендә армиягә алынган егетләрне ут эченә озатучыларны җавапка тарту турында әмер бирде, материаллар хәрби прокуратурага җибәрелде.

Тарихта бер илгә дә кертелмәгән санкцияләр кырыйсында яши башладык. Хәтта конфликтка нейтралитет белдергән дәүләтләр дә Россия белән кайбер икътисади элемтәләрне өзәргә мәҗбүрләр. Икътисад фронтыннан бер генә уңай хәбәр бар: кайбер тәбәкләрдә бензинга бәяләр төшә. Чит илләрнең фармкомпанияләре Россия базарын ташламыйлар. Монысы да яхшы хәбәр, чөнки алар да бездән китсәләр, сәламәтлек белән бәйле зур проблемалар туарга ихтимал иде. Генпрокуратура ажиотаж нәтиҗәсендә күтәрелгән дару бәяләрен тикшерергә ниятли. Доллар курсы күтәрелү сәбәпле, кыйммәтләнү булыр инде ул берникадәр, әмма өметләнік: бернинә тапкыр ук түгел. Югыйсә үзебездә җитештерелгән товар бәяләрен дә күкка чөя башлады бит кайберәүләр.

Проблемалар ташкыны көннән-көн артыра мөмкин. Аларны кисәтүнең һәм чишүнең иң яхшы ысулы: сөйләшүләр өстәлендә уңышлы килешүгә ирешү. «Худой мир лучше доброй ссоры» дигән рус әйтеме бүген алгы планга чыга. Владимир Путин да инде сөйләшүләрдә өметле чаткылар барлыгын әйтә. Әлегә ике ил делегациясе очрашуларны онлайн форматка күчерделәр. Кремль лидерының Зеленский белән очрашуга каршы түгеллеге хакында да мәгълүматлар бар. Монысы аеруча әһәмиятле, чөнки соңгы килешү лидерларның имзасы белән генә расланa ала. Россия делегациясе вәкиле, депутат Слуцкий сөйләшүләр турында: «Алгарыш ике делегациянең дә бердәм позициясенә үсеп, имза салу өчен документка әверелергә мөмкин», – диде. Американың дәүләт секретаре урынбасары Венди Шерман: «Россия Украина белән җитди сөйләшүләргә әзерләнеп күрсәтә», – ди. Украина вәкиле Михаил Подоляк та Россия ягының Украина тәкъдимнәрен игътибар белән тыңлавын һәм ультиматумнар куймавын әйтә. Шулай булгач, Путин һәм Зеленскийның оченче ил мәйданында очрашып, солых турында килешү имзалавы ихтималлыгы арта. Әмма хәл әлегә киеренке кала. Россия ягы Украинага Көнбатыштан корал китерүче конвойларга һөҗүм итү белән янады. НАТО блогы исә андый һөҗүм була калса, бу блокның кумәк оборона турындагы килешүнең бишенче статьясына туры килачәк дип кисәтте. Бишенче статья НАТОның бердәм рәвештә җавап бирүен таләп итә. Димәк, масштаблы зур конфликт башлану куркынычы да юк түгел. Улчәү солых ягына таба авышса, кыска вакыт эчендә киеренкелек кими башлар иде. Санкцияләр тиз генә алынмас алынуын, әмма бераз йомшартылыр. Икенче вариант турында уйлыйсы да килми.

Бәя дә үсмәсен, эшсезләр дә артмасын

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Хезмәт базары

Республикада рәсми төстә теркәлгән эшсезләр саны 10,1 мең кешегә җиткән. Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренчә, хезмәт базарында киеренкелек барлыкка килү куркынычы да бар. Шул ук вакытта ил базарыннан китәргә карар кылган чит ил оешмалары эш урыннарын да, эшчеләргә дигән хезмәт хакын да саклап калырга вәгъдә итә. Министр эш урыннарына бәйле вазгыятьне даими күзәтчелек сорый дигән фикердә.

– Федераль министрлык белән берлектә хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыруга матди ярдәм бүлеп бирүне хәл итәргә кирәк, – диде ул бу уңайдан.

Сорауларны уртага салып хәл итәр чак. Министр оешма-предприятиеләрдә барлыкка килгән проблемаларны вакытында хәбәр итеп, аннан чыгу юлларын бергә эзләү кирәклеген искәртте.

Шунысы да бар: вазгыятьнең киеренкелеге дә озак вакытка сузылырга мөмкин. Бу җәһәттән санкция кертелгән илләрдән кайтартыла торган продукциягә алмаш табу бурычы тора. Министр моннан чыгу юлын өч юнәлештә күрә.

– Беренчедән, башка илләрдән кайтарту эшен оештырырга кирәк. Транспорт һәм Сәнәгать министрлыклары исә оешмаларга Россия тимер юллары катнашында логистика эше белән ярдәм итәргә тиеш. Икенчедән, төбәкара кооперация булдырырга. Өченчедән, республикада импортны алыштыру өчен продукция җитештерүне оештырырга, – диде Мидхәт Шаһиәхмәтов. Моның өчен предприятиеләрнең булдыра алганча федераль үзәк күрсәткән барлык ярдәм чараларында катнашуы кирәк. Әйтик, система барлыкка китерүче оешмаларга (ә Татарстанда аларның саны (барлык филиал, холдингларны исәпкә алып) – 137), кредитларны реструктуризацияләү яки яңаларын алу өчен дәүләт гарантияләре, чыгымнарны кайтару өчен субсидияләр каралган.

Файдаланырга кирәк!

Ярдәм чараларының зур өлеше мәгълүмати технологияләр тармагына кагылды. Федераль үзәк аларны салымнан һәм тикшерүләрдән азат итәчәк. Бу мөмкинлектән Россия Цифрлаштыру министрлыгы аккредитациясен узган оешмалар файдалана ала. Татарстанда исә бу уңыш 3 мең оешманың 243енә генә тәти. Мидхәт Шаһиәхмәтов ярдәм чараларыннан файдалану өчен мөмкин булганча күбрәк оешмаларны аккредитация узарга өндәде.

Кризиска каршы федераль ярдәм чаралары эшкуарларга да кагылачак. Мидхәт Шаһиәхмәтов искә төшергәнчә, зыян күргән тармакларда (70 төр) эшчәнлек алып барган эшмәкәрләр кредит каникулыннан файдалана ала. Ул алты айга бирелә. Шулай ук бизнес вәкилләрен ел азагына кадәр күзәтчелек органнарының тикшерүләреннән азат итәчәкләр.

Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, бизнес ихтыяҗларын исәпкә алып, республика дәрәҗәсендә ярдәм чаралары исемлеге әзерләнгән. Бу – микрозайм шартнамәсе буенча бурычны кичектереп тору, үзмәшгульләр өчен җиһаз сатып алуга субсидия бирү, сәнәгать паркларының инфраструктурасын үстерү.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯЛГАН СҮЗДӘН САКЛАСЫН

Дөньяда барган вакыйгалар аркасында республикада мәгълүмати иминлекне көчәйтергә туры киләчәк. Бу хакта Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстан Иминлек Советының планнан тыш утырышында әйтте. Аның сүзләренә караганда, соңгы арада иҗтимагый-сәяси вазгыятьне какшату өчен ялган хәбәрләр таратыла. Шуңа күрә тотрыклылыкны сакларга, җәмгыятьтәге социаль киеренкелекне киметергә кирәк.

Утырышта Татарстан Иминлек Советы әгъзалары, министрлыклар һәм ведомстволар, Татарстан предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре, шулай ук муниципаль районнар, шәһәр округлары башлыклары видеоконференцэлемтә режимында катнашты. Утырышта шулай ук Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Алексей Песошин катнашты.

Төп сүз республиканың башкарма хакимияте, җирле үзидарә органнары, предприятие һәм оешмаларының мәгълүмати иминлеген тәэмин итү чаралары турында булды.

«Иҗтимагый-сәяси вазгыятьне какшату максатыннан дөрес булмаган, шул исәптән террорчылык куркынычы турында ялган мәгълүмат таратыла. Татарстанда халыкка мәгълүмат басымының сизелерлек артуы күзәтелә, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Безне дошман күргән көчләр мәгълүмати-психологик йогынты ясау өчен һаман саен зуррак көч куя». Президент әйтүенчә, төбәкнең социаль һәм икътисади өлкәләре имин шартларда эшләсен өчен вакытында нәтиҗәле чаралар күрергә кирәк.

tatarstan.ru

Утырышта Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин, Федераль иминлек хезмәтенең республика буенча идарәсе башлыгы Игорь Хвостиков, «Таттелеком» ГАҖ генераль директоры Айрат Нуретдинов чыгыш ясады. Айрат Хәйруллин хәбәр иткәнчә, республиканың мәгълүмат ресурслары Ddos-һөҗүмнәргә ешрак дучар була башлаган. Министр билгеләп үткәнчә, моңа каршы тору эше көчәйтелгән, республикада сайтлар эшендә өзеклек булмасын өчен барлык куркынычсызлык чаралары күрелде.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утызынчы утырышы 16 март көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Дәүләт Советы депутатлары теркәү Дәүләт Советы бинасында 16 мартта 8.00 сәгатьтән башлап хәл ителә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Авыл тоткалары җыела

16–18 март көннәрендә Казанга татар авыллары эшмәкәрләре җыела. Өч көн рәттән Бөтендөнья татар конгрессы X Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенын уздыра. Быел әле чарага Россиянең 40 төбәгеннән, шулай ук Татарстаннан 500 кече бизнес вәкиле һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре җыелачак.

Кунаклар беренче көнне фикер алышу мәйданчыкларында эшләячәк. Анда татар авылларында милли тормыш һәм рухи тәрбия, заманча инновацион технологияләр ярдәмендә җиләк-җимеш культураларын массакүләм үстерү, татар халкының традицион тәрбия системасын торгызу һәм яшьләрне базар шартларында эшмәкәрлек идеяләрендә тәрбияләү, авыл эшмәкәрләре җитештергән продукцияне эшкәртү һәм сату мәсьәләләре хакында сөйләшәчәкләр. Моннан тыш, эшмәкәрләр пленар утырышта катнашачак, шулай ук Буа районына сәфәр кылачак. Россия төбәкләрендә җитештерелгән продукция һәм халык кәсебе товарларыннан торган «Татар базары» күргәзмә-ярминкәсе дә оештырылачак.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров матбугат очрашуында әйтүенчә, әлеге җыен тулы канлы хәрәкәткә әверелгән.

– Татар авылының киләчәге дигән вакытта мин беренче чиратта татар эшмәкәрләренең эшчәнлеген әйтер идем. Бүген дөньяда барган вакыйгалар йогынтысында азык-төлек куркынычсызлыгы көн кадагында тора. Безнең халык үзебездә җитештерелә торган азык-төлек белән тулысынча тәэмин ителгән. Һәм монда эшмәкәрләрнең роле зур, – диде ул.

Данис Шакиров сүзләренә караганда, җыенга татар авылларын үстерүгә зур өлеш кертүче, милли тормышка битараф булмаган эшмәкәрләр җыелачак. «Теләк белдергәннәр тагын да күбрәк иде, ләкин авырлар булу сәбәпле, саннарны чикләргә туры килде», – диде Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Марс Тукаев. Иң күп кеше, елдагыча, күршеләребез Башкортстаннан киләчәк. Аннан 68 делегат катнашыр, дип ниятлиләр.

Бөтендөнья татар конгрессының татар эшмәкәрләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Уразаев «Татар базары» күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге белән таныштырды. Ул Россиядә 4500 татар авылы барлыгын искә төшерде. Шуларның 2000е – Татарстанда, 1500е Башкортстанда булса, калган 1 меңе – башка төбәкләрдә.

– Әлеге авыллар кара туфракта утырган. Бу – иң зур байлык. Ә икенчесе – су, өченчесе – өч буынны саклаучы хәрәкәт. Бүген татар авылларында авыл җирләренең 75 проценты эшкәртелми. Бу җинаятькә тиң. Авыл эчендәге җир бүген – органика, барлык коммуникацияләр кергән иң кыйммәтле җир. Бу авылларны югалтабыз икән, без иң кыйбатлы органик җирләрне югалтачакбыз. Җирне эшкәртелмәгән илнең баеп алга киткәне юк әле. Дөньядагы бөтен кара туфракның 63 проценты – Россиядә. Ә без, татарлар, шушы кара туфрак өстендә яшибез. Шуңа күрә Башкортстан юнәлешендә дә проектыбыз бар, – диде Фәрит Уразаев.

Аның фикеренчә, республика бакчачылык начар үсеш алган. «Бакчачылык – Татарстанда иң зәгыйфь юнәлеш», – диде ул.

Шуңа күрә быел җыен кысасында беренче тапкыр «Бакчачылык һәм бакча культуралары» номинациясе гамәлгә кертелгән.

– Россиядә бакчачылык юнәлешендә азык-төлекнең 12 проценты гына җитештерелә. Хәзер санкцияләр кертелгәч, җиләк-җимеш җитештерү бездә тагын да начараячак, – дип искәртте Фәрит Уразаев. Шул ук вакытта Татарстанда да бу юнәлеш буенча уңышлы эшләп килүче бернинә эшмәкәр барлыгын әйтте. Мәсәлән, Буа һәм Чүпрәле районнарында фермерлар зур алма бакчалары булдырды.

Моннан тыш ул күргәзмәдә «Сәламәт милләт» блогына да игътибар юнәлтүне сорады.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧИЯЛЕККӘ ЮЛ КАЙДАН?

Авыл капкасы

Актаныш районының Чиялек авылы халкы, без бетәбез, дигәннәрдән түгел. Югыйсә монда кышын 10нан артык кеше генә яши. Үз куңелләрен күрә беләләр: 80нән узган Данил бабай гармун тартып сайларга бара. Җиңү бәйрәмендә бергәләшеп ботка пешерәләр. Читтә йөргәндә дә Чиялек исләреннән чыкмый. Радик исемле якташлары Эльбрус тавына «Чиялек – Актаныш – Татарстан» дип язылган әләм күтәреп менгән хәтта.

Кечкенә авылларның язмышлары бертөрле диярлек. Алар – өлкәннәр кулында. Чиялектә дә шулай. Авылның иң өлкән кешесе Сахирә әбигә – 97 яшь. Туксаннан узганнар тагын бар әле. Яшьләр юк, парлылар сирәк. Чиялектә йортлар саны 20дән артык. Кышын яртысы буш торса да, җәен башкалардының да йозаклары ачыла. Шәһәргә китүчеләр дә авылга сукмакны онытмый. Дөрес, кайчак буран юлларны бөтенләй күмеп китә. Ул чакларда авылга кайта, кайтсаң, китә алмыйсың. Менә шунысы яман. Ә чиялекләләр бер-берсе белән күрешеп яшәргә өйрәнгән. Алар өчен бер кайтып хәл белешүдән дә кадерлерәк нәрсә юк. Каһәр, 8 март алдыннан чыккан буран юлларны томалап бетергән. Шуңа күрә кайберәүләр туган авылына кайта алмаган. Ә кайтканнар белән бергәләшеп, кышкы спартакиада үткәргәннәр. Авыл уртасына кызыл әләмнәр элгәннәр, багана «финиш» дип язганнар. Тирләп-пешеп чаңгы шугаңнар. Авыл читендә – чаңгы эзләре. Эзләр буч яхшы, димәк, тормыш бар. Ел саен булмаса да, Сабан туен да уздыралар. Концерт куял, шашлык пешереп, ял итәләр. Шуңа күрә Чиялектә шау-шу бөтенләй тынмаган әле. Бала-чагасы булмаса да, кәефне күтәрүче, ямь өстәүче оптимист кешеләре бар. Тирә-ягын чиялек капкаган авылда кыпкызыл чияларне күз алдына китерегез әле. Авылга юкка гына шундый исем кушылмаган. Кешеләре дә шундый янып торган, җәтеләр.

Энҗе апа белән Гали Ярмөхәммәтовлар 2013 елда Себердән күченеп кайтканнар. Гали абыйның туган авылы бу. Әти-әнисе нигезенә яңа йорт җиткезгәннәр. Шәһәрдә фатирлары булса да, китәселәре килми. Урман уртасындагы авылның саф һавасы гына ни тора! Җәен бер чиләк җиләкне шунда ук тутырасың. Йортларга газ, су кергән.

– Клуб юк, дип аптырамыйбыз. Сайлауны да бик күңелле үткәрәбез. Өлкәннәр көннәндә урамда табын корып, әбибабайларны чакырабыз. Сәҗидә апа Сабайкова моңа кадәр авылга җәен генә кайтса, быел кышны да безнең белән үткәрде. Шуның белән бергәләп авылның бетермәскә җан тартышабыз. Туган нигезләренә балалары, оныклары кайта. Чаңгыны да бергәләп шудык, бик күңелле булды, – ди Энҗе апа.

Иске Айман авыл җирлеге башлыгы Марсель Әхмәтханов әйтүенчә, бу авылда оптимист кешеләр генә яши.

– Зур авылларда халыкны чараларга алып бара башласаң, качып бетәләр. Чиялектә алай түгел. Синең каршыңа үзләре гармун тотып, җырлап киләләр. Башка җирдә машина чакыртып та сайлауга алып барып булмый, без картайдык, диләр. Ә монда чәйгә кадәр дәшәләр. Җиңү бәйрәмендә кунакка кайтучы балаларга хәрби киемнәр кидертеп, һәйкәл янына барабыз. Патриотик тәрбия бит бу. Авыл халкы ботка пешерә. Һәйкәлне дә авыл халкы акчасына торгыздык. Башта бер авылга алып барып, аларга проектын күрсәттем. Барысы да хупладылар. Зират коймаларын да бергәләп тотканнар, – ди Марсель Әхмәтханов.

Авылда бүген клуб та, кибет тә, мәктәп тә юк. Мәктәп беткәч, өч чакрым ераклыктагы Минзәлә районының Татар Мөшегесе авылына барып укыганнар. Балалар тумый башлагач, социаль объектлары да калмаган. Авыл кешеләре аның өчен аптырамый. Барынның да бигрәк юл өчен борчылалар. Юл булса, авылга кайтып торыр идем, диючеләр дә бар икән.

– 8 Март бәйрәменә кайта алмадым шул. Кайтып торма, буран, юл юк, диделәр. Туган нигездә апа яши. Әткәй – кибеттә, әнкәй гомер буе почтада эшләде, хәзер алар мәрхүм инде. Туган авыл барыбер сагындыра, – ди Теләче районындагы яшәүче Клара Мансурова. – Яз-көз авылга керү бик уңайсыз. Машинаны күрше авылда калдырып кайталар. Асфальт сорамыйбыз, таш түшәсәләр дә, бик риза. Юл ачылганда, автокибет иппен, кирәк-ярагын китерә. Фельдшер айга бер тапкыр килеп китсә, яхшы булыр иде. Чиялек авылына керә торган күрсәткеч тә юк, анысын да куярга кирәк.

Марсель Әхмәтханов юл ачылмауның сәбәбен ике тәүлек котырган көз ачмаслык буранга бәйләп аңлатты.

– Бүген килсәгез, ялтырап тора, хет йомырка тәгәрәт. Юлларны һава торышына карап чистартабыз. Куркынычсызлык буенча да алар ачык булырга тиеш. Күәтле техника кирәк. Мин аны «Әнәк» агрофирмасыннан алып торам. Рәхмәткә түгел, әлбәттә. Элеккеге заманнар бетте. Авыл халкының үзара салым акчасы юлны ике тапкыр чистартырга гына җитә. Барлыгы 6 мең сум акча җыела. Шуны юлга, суга, яктыртырга тотарга кирәк. Юл артыннан өч ел йөрим инде. Февраль аенда башкарма комитет җитәкчесе белән дә сөйләштек. Кар эрегәч, үзем килеп карыйм, диде. Җәйгә таш җәярга хыялланабыз, ничек булыр. Фельдшерны үз машинама утыртып алып барам. Һәр әбибабай белән күрешеп, хәлен белешеп чыгабыз, – ди Марсель әфәнде.

Шәһәргә киткәннәргә авылның әрменә кадәр тансык хәттә. Ә моржадан чыккан төтен исе ничек тәмле! Авыл урамында яткан ат тизәкләренә дә борын җыерып карамыйсың. Саланың һавасын, суын чагыштырырлык та түгел. Балаларына барып торган әби-бабайларның түземлеге озакка җитми. Авыл дип чәбәләнә башлыйлар. Чиялек картларының да беркая да китәсе килми. Тавык-чебеш асрап, ишегалдында кыштырдап йөри алсалар да, бик бәхетле алар. Балаларына да шарт куйганнар: «Йә мине алып китмисең, йә авылга үзегез кайтып торасыз!»

Сәрия МИФТАХОВА

ОЛУГЛАРЫБЫЗНЫ ОЛЫЛАУ

2021 ЕЛДА «ҖЫЕН» ФОНДЫ НӘШЕР ИТКӘН КИТАПЛАР ТУРЫНДА

2000 елдан «Җыен» фонды «Татнефть» оешмасы ярдәме белән чыгарып килә торган «Шәхесләребез» сериясе китаплары – озак елларга сузылган өзеклектән соң халкыбызга үзенең мәшһүр шәхесләрен кайтаруы белән үзенчәлекле.



Инде чикләүләрдән соң бераз исеме ишетелә башлаган яки тар даирәдә генә билгеле булып кала килгән бик күп фикер ияләре, сәясмәннәр, иҗтимагый эшлеклеләр, галимнәр, сәнгатькярләр, иҗатчылар хакында тулы фәнни-публицистик мәгълүматны беренче булып шушы китаплар татар дөньясына җиткерде. Фатих Кәрими (2000), Гайнетдин Әхмәров (2000), Габдрахман Гомәри (2002), Хөсәен Фәезханов (2006), бертуган Туйкиннар (2007), Һади Атласи (2007), Җамал Вәлиди (2010), Мәрҗани (2010), Габдерәшит Ибраһимов (2011), Салих Сәйдәшев (2017), бертуган Хөсәеновлар (2018), Таҗетдин Ялчыгол (2019) һ.б. бик күп исемнәр, аларның эш-гамәлләре, фәнни һәм мәдәни иҗаты шулай татар мәдәниятенә кабат килеп кушылды, аның аерылгысыз бер өлеше булып яши башлады. Мөхтәрәм галим Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов инициативасы белән башланган бу игелекле эш ел саен татар халкының 3–8 шәхесе хакында өр-яңа китап булып шәхесләребез хәзинәсен баетып килә.

2021 ел да бу асыл дисбегә төймәләр тезүне дәвам итте. «Мәҗит Гафури» фәнни-популяр җыентыгы шигърияттә Тукай йолдызлыгының иң якты йолдызларыннан булган, XX йөз башы һәм совет дәвере татар әдәбиятының күренекле прозаигы һәм журналисты иҗатына багышлана. Китапны төзүчеләр – филология фәннәре кандидатлары Айгөл Ганиева һәм Алсу Хасавнех.

Җыентыкта әдипнең укучыга моңарчы таныш булмаган күп кенә әсәрләре, хатлары, мәкаләләре дә урын алу, шулай ук төрле чор каләм әһелләренең, галимнәренең аның турындагы истәлекләре һәм фәнни-публицистик язмалары бирелү Мәҗит Гафури иҗатына һәм шәхесенә карата үзгә бер караш тудыра. Әйтик, шагыйрьнең хатыны Зөһрә ханымның шагыйранә тел белән язылган беренче күрешү-очрашулар, мәхәббәт һәм гаилә кору тарихын тасвирлаган истәлек язмасы үзе генә дә без белә торган Гафури сурәтен тамырдан үзгәртергә сәләтле!

Укучыга тәкъдим ителә торган бу хезмәттә язучы тормышы-иҗатына караган аз билгеле материалларны барлау, аның үз васыятен үтәп, Казанда саклана торган бай фондындагы моңа кадәр билгесез кала килгән текстлар халыкка җиткерелү тагын бер мөһим мәсьәләгә ачыклык кертә: шигъриятендә дә, прозасы, публицистикасында да – татар милләте хәлен, ваемын, кайгыларын һәм өметләрен җырлаучы, аның киләчәген кайгыртучы, XX йөз башындагы милли яңарышка юл күрсәтүче, татар әдәбиятының әйдаманы, милләте белән дә, иҗаты белән дә, иң беренче чиратта, татар язучысы, татар зыялысы, татар фикер иясе булган шәхеснең Башкортстанда яшәп, башкорт совет әдәбиятының нигезләрен салуда катнашуын аермачык билгели.

Икенче китап – «Композитор Яруллиннар» фәнни-популяр җыентыгы – татар югары музыка сәнгатен мәдәният мәйданына чыгарган Яруллиннар: аталы-уллы Заһидулла, Фәрит, Мирсәетнең тормыш юлына һәм иҗатына багышлана. Китапны төзүчеләр – сәнгать фәннәре кандидатлары Айгөл Софийская һәм Лилия Сәрвәрова.

Татар профессиональ музыкасына нигез салган династия бу. Җыентык шушы гаиләнең өч күренекле вәкиле турында да гаять күп, кызыклы материаллар туплап эшләнгән. Исеме күп кенә очраклы һәм гаҗәеп хәлләр белән уралган Заһидулла Яруллин шәхесе хакындагы беренче бүлек укучыга XX йөз башы мәдәни яңарышы, шул заман шәһәр татар тормышы, аерым шәхесләр хакында да әтрафлы мәгълүмат бирә. Әлеге бүлек белән танышканда, бу шәхеснең, күрәсең, язмышына нәкъ менә татар профессиональ музыкасын гамәлгә кую язылганлыгы хакындагы фикер күңелдән китми. Икенче бүлек – Фәрит Яруллин, аның кыска тормышы, фаҗигале үлеме, илаһи музыкасы турында сөйләү, композиторның татар мәдәниятен дөнья киңлегенә чыгару кебек гаҗәеп эшне башкаруы исә соклану да, горурлык та уята…

Мирсәет Яруллинга багышланган өченче бүлекне татар профессиональ музыкасының совет дәвере тарихы дип тә карарга мөмкин. Шул ук вакытта җыентык олы музыкант һәм композиторны үз халкының мәдәниятенә, татар теленә, тормышына битараф булмаган гамьле шәхес, зыялы һәм ярдәмчел, нечкә күңелле шагыйранә иҗатчы буларак таныта.

Гомумән алганда, җыентыкта укучыны битараф калдыра алмаслык истәлекләрнең, хатларның, Фәрит Яруллинның үлеме белән бәйле эзләнүләрнең дә, композиторның укытучылары, дуслары белән мөнәсәбәтләре, бу гаиләдә Тукайга яки Салих Сәйдәшевкә мөнәсәбәт мотивының да үз урыны бар.

Өченче китап – «Нәкый Исәнбәт» фәнни-популяр җыентыгы – татар мәдәниятендә һәм фәнендә урыны бәхәссез зур булган фикер иясе, галим һәм шагыйрь, драматург, публицистка багышланган. Китапны төзүче – филология фәннәре кандидаты Миләүшә Хәбетдинова.

Җыентыкны, күрәсең, гаять бай архивы, әле басылып чыкмаган хезмәтләре турында легендалар йөргән бу шәхес турындагы хезмәтләрнең беренчесе дип карарга кирәк. Аның кыйммәте – Исәнбәтнең шәхси архивында тупланган хәзинәнең бер өлешен «Шәхесләребез» сериясе китаплары форматында укучы игътибарына тәкъдим итүдә дисәк, ялгышмабыз. Ул галимнең карашларын, холкын-характерын, гыйльми эзләнүләрен шактый әтрафлы күз алдына китереп бастыра. Аеруча автобиографик материаллар бай булып, аларда язучының гаиләсе, аралашу даирәсе дә, чорның катлаулы тарихи-мәдәни картинасы һәм XX йөз башы белән совет дәверенең аерым шәхесләре сурәте (әйтик, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич) дә, гомумән татар дөньясы һәм татарлык мәсьәләләре дә (аеруча «Минем язучы булуымда һәм әдәби эшчәнлегемдә татар хатын-кызының роле» һ.б.) җете төсләрдә күзаллана. XX йөз башы һәм совет чорының рухи атмосферасы, мәдәни тормышы, зыялыларның илдә барган хәлләргә мөнәсәбәтләре һ.б. бик күп өлкәләр белән кызыксынучылар да китапның беренче бүлегендә гаять үзенчәлекле, башка чыганакларда очрамый торган материал таба ала.

Гомумән алганда, Нәкый Исәнбәт тормышы һәм эшчәнлегенә кагылышлы бай, күбесе моңа кадәр басылып чыкмаган материал тәкъдим иткән әлеге җыентык турында әле фикерләр, бәяләмәләр булыр.

Дүртенче китап «Муса Җәлил – документларда» дип атала, төзүчесе – филология фәннәре докторы Рамил Исламов. Мондый җыентыкларның Габдулла Тукайга, Галимҗан Ибраһимовка кагылышлылары дөнья күргән иде. Тагын бер басманың Муса Җәлилгә багышлануы бик дөрес, урынлы-вакытлы, хуплап кабул ителә. Татар халкының батырлыгын, илгә тугрылыгын үлеме белән раслаган шагыйрьнең сугыш һәм әсирлек дәвере шактый җентекле өйрәнелгән булса да, аның 20–30 нчы еллардагы киңкырлы эшчәнлеге, татар әдәбиятын, сәнгатен үстерү өлкәсендәге хезмәтләре, шәхес булып формалашуы – күләгәдәрәк кала килде. Автор-төзүче бөртекләп җыйган материаллар шушы бушлыкны тутыра, Җәлилнең документларда калкуланган сурәтен укучыга тәкъдим итә.

Аерым алганда, «Рәсми хатлар», «Шәхси хатлар» бүлекчәләре укучы өчен аеруча кызыклы булыр дип уйлыйм. Аларда Мусаның актив гражданлык позициясе, бер күренешкә дә битараф кала алмавы, татар мәдәниятен һәм әдәбиятын үстерү өчен хакимият, иҗтимагый оешмалар белән дә, җаваплы урыннарда эшләгән кешеләр яки шәхси танышлары белән дә никадәр масштаблы аралашуы, үзенең шәхсән төрле өлкәләрдә бик күп эшләргә алынып, шуларны җиренә җиткереп башкарып чыгуы ачык күренә. Җәлил батырлыгының, каһарманлыгының чишмә башы турында уйлануларга да этәрә бу документлар. Әйтик, 1937 (!) елны редакциягә язган хатында Җәлил ул чорның күпләрне сындырган тәнкыйтьчесе Ф. Мөсәгыйть белән үзенең «Балыкчы кыз», «Алтынчәч» әсәрләренә нисбәтле бәхәскә керә, дәлилле-төпле итеп хаклыгын исбатлый. Я булмаса Җәлилнең Сталинга, шулай ук Сталин белән Молотовка язган хатларын төрлечә шәрехләп буладыр. Әмма бер нәрсә ачык: автор чын йөрәктән татар мәдәнияте, аның хәле һәм киләчәге турында кайгырта.

Җыентыкка урнаштырылган «Муса Җәлилнең тормышы һәм эшчәнлеге хроникасы», «Муса Җәлилнең тулыландырылган яңа библиографиясе» кебек бүлекчәләр дә Җәлилне өйрәнү фәненә яңалыклары белән килеп кушыла.

Шулай итеп, 2021 ел татар халкының шәхесләре хәзинәсеннән тагын 4 китап белән сөендерде. Нинди шәхесләр бит әле: милли шигъриятебездә беренче булып, хәтта Тукайга кадәр үк, заман сулышын яңарткан Мәҗит Гафури, татар профессиональ музыкасының чишмә башында торган Яруллиннар, фән һәм мәдәният тарихын өйрәнүдә миллилекне эталон итеп алган Нәкый Исәнбәт, батырлык һәм илгә тугрылык символына әверелгән Муса Җәлил… Аларның һәркайсы – татар дөньясының олы горурлыгы.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА

ЯЗМАНЫҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Язмышлар ярында

«ИҢ БЕРЕНЧЕ ӘНИГӘ БАГЫШЛАП БӘЕТ ЧЫГАРДЫМ»

Хис-кичерешләрен төрле кеше төрлечә белдерә. Авырлык-хәсрәтләрне дә, шатлыклы минутларны да һәркем үзенчә күтәрә. Кемдер барысын эченә җыя, кемдер башкалар белән бүлешә, кемдер кулына каләм ала. Балтач районының Салавыч Сәрдегәне авылында яшәүче Разия апа Габбасова да җан әрнүләрен шигырь юлларына сала.

– Әни үлгәндә сигезенче сыйныфта укый идем. Сигез ел авырып, урын өстендә ятса да, аның үлемен бик авыр кичердем. Мин генә түгел, сигез баланың сигезе дә, әтиебез дә нишләргә белмәде, – дип хатирәләргә бирелә Разия апа. – Бик авыр булды. Әти мескен никадәр генә безнең өчен яшәсә дә, әнине барыбыз да бик сагындык шул. Әтигә без гомер буе сокландык: бер авырсынмый әнә шуның кадәр ел әнине, безне карады, хуҗалыкны-тормышны алып барды. Әмма беркайчан сер бирмәде. Дөрес, зуррак балалар аңа барысына булышты. Тик бар җаваплылык аңарда иде бит. Безне үги итмәс өчен кабат өйләнмәде дә. Бар гомерен безгә багышлады. Сагынуга түзә алмыйча, әни үлгән елны аңа багышлап бәет чыгардым. Аннан соң да үзем өчен генә язгаладым әле. Бер кешегә дә күрсәтмәдем…

Бәлки, күрсәткән булса, сәләте барлыгын күргән өлкәннәр аңа укуын дәвам итәргә дә кушкан булыр иде. Ә ул авылда кала. Кырык елдан артык сыерлар сава. Ул эшләгән Сәрдегән фермасы заманында бик данлыклы булды. «Комсомол-яшьләр фермасы дип гел макталдык. Бик күп күчмә байраклар алдык. Шулкадәр күңелле эшләдек. Авыл тулы яшьләр иде. Кичен клуб шау итеп торды», – дип искә ала Разия апа.

Үзе кебек үк тыныч-тәртипле авылдашы Заһир белән гаилә корып, өч бала тәрбияләп үстерә алар. Заһирның апасының ике кызын да үз канатлары астына алалар. Кызларның берсе тормышка чыккан, икенчесе – яннарында.

– Балалар үстергән чакта шигырь язып утырырга вакыт булмады, ничектер онытылып торган кебек булды ул… Пенсиягә чыккач, вакыт күбәйде… Уйланып йөрисең дә, күңелдәгесен язасың… Авылдашларга багышлап та язам.

Разия апаның шигырь язуын күпчелек авылдашлары әле соңгы елларда гына белгән. Үткән ел авылда яңа ФАП ачыла. Шул хөрмәткә ул авылдашларына күп еллар игелекле хезмәт күрсәткән фельдшер Люция Зыятдиновага багышлап шигырь чыгара. Бәйрәмне алып баручылар аны бик хисле итеп халыкка җиткерә. Район башлыгы Рамил Нотфуллин да кем шигыре булуы белән кызыксына һәм соклануын яшерми («сер» шулай ачыла да). Әле алай гына да түгел, шигырьләрен китап итеп чыгарырга тупларга куша, ярдәм дә ышандыра. Инде шигырьләрен туплаган да булалар… Кызганычка, китап мәшәкате икенче планга күчә. Моңа кадәр дә күп югалтулар, сынаулар белән очрашырга туры килгән Габбасовлар үткән җәйдә 33 яшьлек кызлары Алинәне югалта. «Заһирның энесе Заһид тә 33 яшьтә китеп барган иде, Алинәбез дә 33тә иде, – ди Разия апа. – Юньләп авырмаган да килеш бит, аны уйламаган бер минутыбыз да юк, берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласы калды… Тыным бетә, йөрәк кыса дип, Тәтеш хастаханәсенә барган (кызлары Тәтеш районында тормышта була. – **Авт.**), кардиограмма яздырганнар да, иртәгә килерсең, дип кайтарганнар. Өйгә кайткач, хәле авырайган, «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җиткәнче үлгән дә… Балаларын үзебез үстермәкче идек, киявебез белән кодагый, үзебез карыйбыз, диде. Шулкадәр матур яшиләр иде, бер минутта барысы үзгәрде»…

…Тормыш бала чактан сабырлыкка өйрәткән Разия апа бу хәсрәтне дә башкалар белән сак кына бүлешә. Йөрәгендә янган утны ул кәгазьгә төшерә. Бәргәләнгән җанына дәваны да шуннан эзли…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ВТ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

«Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте белән берлектә, «Безнең авыл имамы» дигән бәйге игълан итә.

Соңгы елларда авылларда дини тормыш игътибар үзәгендә. Бу аңлашыла да, авыл – милли һәм рухи тормышыбызның чыганагы. Авылдагы рух тотрыклыгы, хәтта татар теле язмышы да имамнарга барып тоташа.

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:

I урын – 10 мең сум;

II урын – 7 мең сум;

III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.

Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе. Игелекле эшләре белән авылдашларының, якташларының хөрмәтен яулаган бертуган эшмәкәрләр Рафыйк һәм Рәшит Бәхтияровларның эшләрен дәвам итеп, аларның якты истәлеге хөрмәтенә туганнары әлеге игелекле эшкә алындылар. Исегезгә төшереп китәбез: 2021 елда «Ватаным Татарстан» газетасы үткәргән «Шәфкать» бәйгесенең дә төп иганәчесе Бәхтияровлар булдылар.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:

«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин.

Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222 09 70, 8917 927 00 40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында. 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә. Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама, 16+

Ат урынына – трактор

Мамадыш районының Түбән Ушмы авылында яшәүче Илфат Әхмәтҗанов мини-трактор ясаган.

Моның өчен башта тимер кисәкләре җыйган. Кайда нәрсә очрый, берсен дә әрәм итмәгән, төрле машина запас частьларын өенә ташыган. Башкача булмый да, кечкенәдән күңелендә йөрткән хыялын тормышка ашырасы бар бит!

– Тракторның двигателе – «Жигули»ныкы, фарасы – мотоциклныкы. «Запорожец», «Нива» автомобиле запас частьларын да кулландым. Нинди тимер-томыр бар – шул кереп китте, – дип сөйли Илфат Әхмәтҗанов. – Элек атыбыз бар иде. Аны асрамый башлагач, ничек тә бер трактор ясарга иде дигән уй яңарды. Мамадышта эшләп йөргәндә кул җитмәде. Авылга кайткач, тракторны җыярга тотындым.

Хәзер инде берничә ел шуның белән бөтен хуҗалык эшен башкара икән. Кул хезмәтен шактый киметкән трактор. Язын бакча сукалыйлар, тырмалыйлар, бәрәңге утырталар. Җәй буе печән әзерлиләр. Илфат абый аңа печән чаба, җыя торган махсус җайланмалар да ясап куйган. Бәрәңгене дә трактор белән алырга җыена әле быел. Ике рәткә кереп ала торган җайланмасы әзер инде. Кышын да тик тормый. Кар эттереп, көрәп куя икән.

– Күршеләр дә сорап тора кайчак. Без бик тату яшибез. Бөтен эшләрне бергәләп эшләргә күнеккән. Авылдашларның бакчасын да сукалап бирәм, печәнен дә чабам, кар да эттерәм. Аның бер авырлыгы да юк, – ди Илфат Әхмәтҗанов.

Балта эшләренә дә оста икән. «Ир кешенең кулы эш белергә тиеш. Белмәүчеләр юк ул, өйрәнергә теләмәүчеләр генә бар. Һәр эштә теләк кирәк. Әгәр теләк бар икән, вертолет та җыеп була. Тимер-томыр гына җитсен!» – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әтисе

Рафан Хафиз улы МОРТАЗИН

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокукый идарәсенең закон проектлары эше буенча бүлек мөдире Регина Рафан кызы Мортазинаның авыр кайгысын уртаклаша.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация:
– о структуре и объеме затрат на производство и реализацию товаров (работ, услуг) ООО «Альтернативная энергосбытовая компания»;
– об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

КОТЛЫЙБЫЗ!

Зәй районының Түбән Биш авылында гомер итүче кадерле әтиебез Гакиф Шакирҗан улы ШИҺАПОВның 5 мартта гомер бәйрәме – туган көне булып узды.

Газиз кешебез, кадерле әтиебез!

Шундый зур һәм якты бәйрәмең көнендә без сиңа ихлас котлауларыбызны юллыйбыз. Кадерле әтиебез, сиңа булган теләкләребезнең иң мөһиме – алдагы гомер елларында тормыш юлларын иминлектә, сау-сәламәт булып, бәхетле көннәрдә, шатлык белән үтәргә язсын. Киләчәктә дә балаларың, оныкларың, кардәш-туганнарыңның шәфкатен, мәрхәмәтен, игътибарын һәм ихтирамын тоеп, хәләл җефетең – әнкәебез белән хәерле, тыныч картлык насыйп булсын иде.

Иң изге теләкләр белән, кызың,
улларың, киленнәрең, оныкларың.
Бу теләкләргә тормыш иптәшең дә кушыла.

Спорт

«Ак барс»ны ялга җибәрделәр

Үзгәрергә туры киләчәк. «Ак барс» икенче ел рәттән «Авангард»ка оттырып, Гагарин Кубогы өчен көрәштән төшеп калды. Уенчылар гына түгел, остазлар сафында да үзгәрешләр буласын чамалавы кыен түгел. Баш тренер Дмитрий Квартальнов та моңа әзер булуын әйтте.

Казан командасы беренче өч матчны оттырып, аннары икесендә җиңгәч, «Ак барс» тамашачысының күңелендә өмет уянган иде. Дүртенче һәм бишенче матчларда якташларыбыз көндәшкә баш күтәрергә дә ирек бирмәде. Ахыр чиктә «Авангард»ның баш тренеры Боб Хартли башта Казан уенчыларын куркыта башлады, аннары хөкемдарлар янына барып тавыш чыгарырга маташты. Кыскасы, чын плэй-офф башланды. «Ак барс» үз эшен дәвам итәр, бертуктаусыз һөҗүм итеп, сафлары сирәгәйгән Омск – Балашиха сакчыларын эштән чыгарыр дип өметләнделәр. Әмма барып чыкмады. Алтынчы матчта Дмитрий Квартальнов уенчылары бер алка да кертә алмады. Казан командасында уенның язмышын үзгәртергә сәләтле кеше табылмады. Матч тәмамлангач исә Квартальновның көндәш уенчыларның кулын кысарлык та көче калмаган иде. «Хәзер инде нәрсә әйтсәк тә мәгънәсе юк. Эш көндәшнең осталыгында түгел, аларның дәрте, җиңү теләге күбрәк иде. Безгә менә шул җитмәде. Әнә шул барысын да хәл итте инде», – диде баш тренер алтынчы очрашудан соң.

Шулай итеп, «Ак барс» икенче ел рәттән Гагарин Кубогы өчен көрәштән төшеп калды. ЦСКА белән «Локомотив»та җиңү яулый алмаган Дмитрий Квартальнов Казанда да үз теләгенә ирешә алмады. Моның шулай буласын ул әле Казанга килгәч тә әйтүчеләр булды, кызганыч, аларның фаразы чынга ашты. «Ак барс»ның составы башка командалардан кайтыш дип әйтеп булмый. Әмма Казанда зур хезмәт хакы алучы хоккейчылардан команда укмаштыра алмый азапландылар. Узган сезон ахыры чит ил уенчыларының бозга чыкмавы белән истә калды. Быел исә команданы үз артыннан ияртә алырлык егетләр табылмады. «Барысын да яхшы аңлыйм. Нәтиҗә канәгатьләнерлек түгел. Җитәкчелек карар кабул итәр, мин барысына да әзер», – ди Квартальнов.

Әмма «Ак барс»ка баш тренерны алмаштыру гына ярдәм итмәячәк. 2018 елда Гагарин Кубогын откан команданың нигезе җимерелеп бетте. Җиңү яуларлык яңа состав тупларга туры киләчәк. Воронков, Сафонов һәм Галимовка гына өметләнеп булмый бит инде. «Ак барс»та гына түгел, гомумән, КХЛда соңгы вакыйгалар аркасында зур үзгәрешләр булырга мөмкин. Киләсе сезонның нинди буласы чит ил уенчыларының килү-килмәвенә, ә иң мөһиме – клубларны финанслау мәсьәләсенә дә бәйле булачак. Аңа кадәр исә быелгы җиңүчене ачыклыйсы бар. «Ак барс» тамашачысы хәзер хоккейны тынычлап карый алачак.

ak-bars.ru



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

БУ ЮЛЫ КАЗАНДА КӨРӘШӘБЕЗ

Җәлил истәлегенә

Ниһаять! Бу атнада татарның иң көчле егетләре Казанга җыела. 18–19 март көннәрендә «Ак барс» көрәш сараенда герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш турниры уза. Татарстан Көрәш федерациясенең зур ярдәме белән бәйгегә әзерлек эшләре төгәлләнеп килә.

59 нчы ТУРНИР
18–19 МАРТ,
КАЗАННЫҢ
«АК БАРС»
КӨРӘШ САРАЕ

Татарстан көрәш федерациясе | Татарстан Спорт министрлыгы | «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе

АЧЫЛУ ТАНТАНАСЫ 18 МАРТ КӨННЕ КӨНДЕЗГЕ СӘГАТЬ 12гә БИЛГЕЛӘНГӘН

Шулай итеп, соңгы елларда Чаллы, Әлмәт, Биектау, Зәй, Актаныш, Минзәләдә узган бәйге кабат Казанга әйләнеп кайтты. Көрәш җәмәгатьчелеге беренчесе әле 1964 елда ук узган һәм иң мәртәбәле турнирлардан саналган бәйгенең февраль уртасында, Җәлилне искә ала торган көннәрдә оештырылуына күнеккән. Быел исә мәгълүм сәбәпләр аркасында ярышны уздыру вакытын бер айга кичектерергә туры килде. Көрәшчеләрнең дә, тамашачының да сәламәтлеген кайгыртып кабул ителде әлеге карар.

Вакыты үзгәрсә дә, мәгънәсе шул килеш кала бәйгенең. Яңа батырлар ачыклана, элеккеләре искә алына бу ярышта. Җәлил бәйгесе җиңүчене ачыклаудан гына гыйбарәт түгел. Биредә көрәш җәмәгатьчелеге тарихны да барлый. Гадәттәгечә, бу турнирда узган елга нәтиҗәләр дә ясала.

Хәтерләсәгез, узган ел Минзәләдә узган ярышта 48 командадан 391 көрәшче бил алышты. Ахыр чиктә Әлмәт егетләре җиденче мәртәбә кубокны үзләренә алып кайтып китте. Тарихка күз салсак, 1964 елда узган тәүге турнирда Сарман командасы беренче булган. Аннан соң күчмә кубок Буага киткән, өченче елны Чистайга да барып кайткан. Шуннан соң ике ел рәттән Актаныш көрәшчеләре макталган. Шулай да турнир кырык елдан артык үткәрелү дәверендә иң зур уңышка Балтач егетләре иреште. Алар бу турнирда 13 тапкыр (1977, 1980–1984, 1988, 1989, 1991, 2000, 2002, 2003, 2005 елларда) җиңүче исемен алганнар. Чаллы көрәшчеләре исәбендә тугыз җиңү бар. Түбән Кама егетләре биш мәртәбә кубок иясе булды. Сүз уңаеннан, Түбән Кама көрәшчеләренең шушы көнгә кадәр берәү дә кабатлый алмаган искиткеч бер казанышы бар. 1976 елда әлеге команданың биш көрәшчесе дә (ул чагында ярышлар биш авырлык үлчәвендә уздырыла) үз авырлыкларында беренче урынны алуга ирешкән. Алар – Нариман Әхмәтшин, Наил Зәйнуллин, Михаил Минеев, Фазыл Әхмәтҗанов һәм Данил Галиев.

Зәй һәм Теләче көрәшчеләре газетабыз турнирында өчәр мәртәбә җиңү яулады. Тукай, Мамадыш, Актаныш районнары ике тапкыр уңышка ирешсә, Арча, Саба, Кукмара, Буа, Сарман, Чистай, Питрәч, Яшел Үзән, Казанның Вахитов, Мәскәү, Киров районы командалары берәр тапкыр бәйрәм иткән.

Быел кем беренче булыр? Узган ел батыр исемен яулаган егетләрнең хәлен белештек.

Искәндәр МОРТАЗИН (Әлмәт):
– Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы турнир – иң данлыклы һәм көчле көрәш ярышларының берсе, миңа калса. Елдагыча, ныклап әзерләнәбез һәм, әлбәттә, җиңәр өчен киләбез. Башка егетләр ничектер, әмма минем максат шундыйрак. Быел әлеге турнирда унынчы мәртәбә катнашам икән инде. Өч тапкыр батыр калдым, ике мәртәбә призлы урын яуладым, Аллага шөкер. Соңгы ел эчендә спорт өлкәсендә әллә ни яңалыкларым булмаса да, шәхси тормышымда үзгәрешләр җитәрлек: узган җәйдә тормыш иптәшем Рузилә белән язылыштык.

Эльдар ХӘМИТОВ (Чаллы):
– Узган елгы турнирда 100 кило авырлыкта батыр калган идем, быел да шул үлчәүдә көрәшергә иде. Тик авырлыкны киметәсе бар – төп максат әлегә шул. Һәм... кемнең җиңәсе килми ди? Мин дә җиңәр өчен киләм, Алла боерса. Быел Чаллы җыелма командасын беренче урынга күтәрергә иде инде (узган ел егетләр команда беренчелегендә икенче булды. – **Ред.**) Егетләр дә шактый нык әзерләнә дип беләм. Хәер, кемнең кем икәне, ел буе кемнең нишләп йөргәне – барысы да келәмгә чыккач беленә инде.

Өйдә малай үсә. Бер яшь тә ике айлык булды менә. Келәм белән гаилә арасында йөреп торыш, зурлап сөйләрлек яңалыкларым юк.

Муса ГАЛЛӘМОВ (Лаеш):
– Әлеге турнирны быел да калдырмаска иде инде. Ялгышмасам, быел 11 нче мәртәбә катнашам, шуларның бишесендә батыр калдым. Бу нәтиҗәгә бик сөенәм мин, чөнки Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы бу турнирда һич югы беренче өчлеккә эләгү балачак хыялым иде. Чыгышым белән чит республикадан булгач, җиңүчеләргә кызыгып карадым. Чөнки чит төбәкләрдән килгән көрәшчеләрнең бик сирәге генә батыр кала иде. Шул аз санлы көрәшчеләрнең берсе булуым белән горурланам.

Быелгы ярышларда да имгәнмичә, җәрәхәт алмыйча гына матур көрәш күрсәтергә телим. Узган елгы Татарстан чемпионатының финалында җәрәхәт алдым – бу сезон шунысы белән үкенечле булды. Ә шәхси тормыштагы яңалыкларга килгәндә, сөенерлек вакыйгалар бар. Быел мин дүртенче тапкыр әти булдым. Гаиләбездә дүртенче кыз бала туды!

Ленар САДЫЙКОВ (Чаллы):
– Ният бер генә – җиңәргә дип киләбез. Элек әлеге турнир үзебезнең шәһәрдә – Чаллыда уза иде. Кечкенәдән күреп, ишетеп үстем. Бил алышуларны карарга еш килә идем. Ул чакта ук бик масштаблы, мәртәбәле, бик матур ярыш буларак истә калган. Бүген дә шул биеклектә ул. Беренче тапкыр катнашкан көнем дә исемдә. Ул чакта да Чаллы келәмендә бил алыштык. Зурлар арасында көрәшә башлаган гына мәлем иде. Әллә беренче, әллә икенче ярышым булган микән? Бик борчылганым хәтердә. Узган ел батыр калгач, быел инде артык каушамыйм. Шул ук вакытта җаваплылык хисе дә артты – сынатмаска кирәк.

Узган елгы Татарстан чемпионатында Рафаэль Кәлимуллин белән көрәшергә туры килде. Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы турнирның узган елгысында мин батыр калсам, чемпионатта ул җиңде. Алда безне «матч-реванш» көтә, оттырмаска иде бу юлы.

Раил СӘЛАХЕТДИНОВ (Кукмара):
– Егетләрнең һәркайсы, башкаларны җиңәм, дип киләдер инде. Мин дә шулай. Быелгы турнирда икеләтә тырышырга туры киләчәк – узган елгы батыр исемен акларга иде. Җиңүләргә алай җиңел карамыйм, алар зур җаваплылык өсти. Синнән гел җиңү көтә башлыйлар. Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы көрәш турнирында әле дүртенче мәртәбә генә катнашам. Беренче тапкыр әлеге ярышларда зурлар арасында көрәшә генә башлаган елны бил алыштым. Шул ук елны икенче урында калдым. Ике тапкыр отканмын да икән. Көрәш дөньясында кайный башлаганда ук бу турнир турында шактый сүзләр ишетергә туры килде. Егетләр ел саен көтеп ала аны, үзем дә шулар рәтендә. Быел Россия һәм Татарстан беренчелеген дә оттым – сөенечле хәбәрләрдән әлегә шулар. Шәхси тормыш исә элеккечә...

Рузил ГАНИЕВ (Әлмәт командасы тренеры):
– Быел да беренчелекне бирмәскә иде инде – егетләр үзләре ни уйлыйдыр. Командада бераз гына үзгәрешләр дә бар. Әйтик, Искәндәр Мортазин соңгы берничә ярышта 65 кило авырлыкта көрәшсә, бу турнирга 70 кило авырлыкта бил алышырга дип килә. Айрат Сәмигуллин да 90 кило авырлыктан 85кә күчте. Шулай ук ярышларга берничә яшь егетне дә алып килеп карыйбыз әле. Кемнәр икәне әлегә сер булсын. Көрәшне үстерү мәсьәләсендә бераз борчуларыбыз да бар. Кайбер командалар хәзер исеме өчен генә килә – аларны кызыксындыру чаралары җитми. Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирында еллык нәтиҗә ясала, якын-тирәдәге төбәкләрдән дә катнашучылар килә. Шуңа да без аңа ел саен ныклап әзерләнәбез.

КУЛЛАР КАЛТЫРЫЙ, МИН ТУКТАМЫЙМ

Әлеге ханымга сокланмый мөмкин түгел. Кайчак без юк кына мәшәкать килеп чыкса, зарланырга тотынабыз. Безгә һаман нидер җитми. Шөкер итә белмибезме шунда. Ә бит авыру килеш тә башкаларга үрнәк итеп куярлык кешеләр бар арабызда.

Казанда яшәүче ДЦП диагнозлы Айгөл Исмәгыйлева әнә шундыйларның берсе. Ул бер дә зарланмый. Гел ниндидер яңалыкка омтыла. Шигырьләр дә яза, рәсем дә ясый, телләр дә өйрәнә.

– Мәктәп-интернатны тәмамлагач, вузга укырга кердем. КФУның журналистика факультетын тәмамладым. Китапханәдә эш тәкъдим иткәч, анда урнаштым. Ипотекага фатир алдым. Китапханәдә 15 елдан артык эшләгәнмен. Минем өчен бу күп инде, – ди ул.

Айгөлнең авыруы тумыштан. Буыннар белән бәйле тагын бер авыруы бар. Әмма сызланулары күп булса да, Айгөл тормыштан ямь табып яши. Кечкенәдән язган шигырьләрен туплап өч китап чыгарганнар.

– 10 җыентыкта минем шигырь-әкиятләрем басылып чыкты. Аллага шөкер, мин башкаларга файда китерә алам. Шуңа сөенәм. Әле узган ел үзем кебек кызлар арасында узган бәйгедә өченче урынга лаек булдым. Минем өчен бу да зур җиңү булды, – ди ул.

Айгөл рәсем ясарга да ярата. Кайчак куллары да тыңламый икән. Тик бирешми, ничек итсә итә, кулын тыңлата. Өч ел элек Коръән китабын укый башлаган. Аны аңлар өчен гарәп телен үзләштергән. Хәзер менә шәмаилләр чигә.

– Театрны да яратам. «Э-моция» студиясендә шөгыльләнәбез. Ике спектакльдә уйныйм. Бу да миңа бик ошый. Рольгә шулкадәр кереп китәм, кайчак авыру икәнемне онытам, – ди ул.

Айгөл кияүдә. Ире дә үзе кебек ДЦП диагнозлы. Икәү булгач, яшәү рәхәт, ди ул.

– Үз фатирыбызда яшибез. Бер-беребезне аңлап торабыз. Ирем дә – акыллы кеше. Авыр сүз әйтми, без юкка-барга ачуланышып, бәхетле минутларны киметмибез. Бик күп чит илләрдә булдык. Чит илдә физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә башка мөнәсәбәт. Анда үзеңне башкалар кебек хис итәсең, – ди Айгөл. – Безнең кебекләргә карата җылы мөнәсәбәт булсын иде. Мин зарланмыйм. Әмма кешеләрнең елмаеп каравын, кирәк чакта кул бирүен телим!

Гөлгенә ШИҺАПОВА



Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 235

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+